**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашкан Россия Федерациясе гражданнарының аерым категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашкан гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү максатларында **карар бирәм**:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы территориясендә даими яши торган Россия Федерациясе гражданнарының түбәндәге категорияләренә 100,0 мең сум күләмендә бер тапкыр акчалата түләү бирергә:

Бөек Ватан сугышы инвалидларына;

«Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән затлардан булган Бөек Ватан сугышы ветераннарына.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә әлеге Указны үтәү белән бәйле чыгымнарны, шул исәптән бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне китертүгә тотыла торган чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне алар социаль ярдәм чаралары ала торган урыннарда бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2026 ел, 28 май
№ 425